| КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ОХРАНЕ ОБЪЕКТОВ КУЛЬТУРНОГО НАСЛЕДИЯ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МӘДӘНИ МИРАС ОБЪЕКТЛАРЫН САКЛАУ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

21.12.2021 г.Казань № 333-П

Татарстан Республикасының Актаныш муниципаль районында урнашкан «Чишмәбаш стоянкасы I» ачыкланган мәдәни (археологик) мирас объектын ачыкланган мәдәни мирас объектлары исемлегенә кертү, чикләрен һәм территориясеннән файдалану режимын раслау турында

"Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләр) турында" 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы Федераль закон, "Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында" 2005 елның 1 апрелендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 12 июлендәге 565 номерлы "Мәдәни мирас объектларын саклау буенча Татарстан Республикасы комитеты мәсьәләләре" карары нигезендә боерам:

1. Бу боерыкка 1 кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районында урнашкан «Чишмәбаш стоянкасы I» археологик мәдәни мирас объектын ачыкланган мәдәни мирас объектлары исемлегенә кертергә (бастырып чыгарылырга тиеш түгел).
2. Бу боерыкка 2 кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районында урнашкан «Чишмәбаш стоянкасы I» мәдәни (археологик) мәдәни территориясе чикләрен расларга (бастырып чыгарылырга тиеш түгел).
3. Бу боерыкка 3 кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районында урнашкан «Чишмәбаш стоянкасы I» мәдәни (археологик) мәдәни мирас объекты территориясеннән файдалану режимын расларга.
4. Мәдәни мирас объектларын исәпкә алу һәм шәһәр төзелеше эшчәнлеге бүлегенә ачыкланган мәдәни мирас объектының чикләре турындагы мәгълүматларны Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрына кертүне тәэмин итәргә.

5. Боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Комитет рәисе урынбасары М.М.Вәлиуллинга йөкләргә.

Рәис И.Н. Гущин

Татарстан Республикасы мәдәни
мирас объектларын саклау
комитетының «_21_» __12__
2021 елның __333-П__боерыгына
3 кушымта

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районында урнашкан «Чишмәбаш стоянкасы I» ачыкланган мәдәни (археологик) мирас объекты территориясеннән файдалану режимын

Археологик мирас объектлары урнашкан җир кишәрлекләреннән файдалануның аерым режимы “Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) турында” 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы Федераль законда (алга таба - 73-ФЗ номерлы Федераль закон) билгеләнгән тәртиптә, 73-ФЗ номерлы Федераль законның 30 статьясында күрсәтелгән җир, төзелеш, мелиорация, хуҗалык эшләре, ачыкланган археологик мирас объектларының сакланышын тәэмин итү, шулай ук гражданнарның күрсәтелгән объектларга керүен тәэмин итү шартларында урманнардан һәм башка эшләрдән файдалану эшләрен башкару мөмкинлеген күздә тота.

Ачыкланган археологик мирас объектлары урнашкан су объектын яисә аның өлешен куллануның аерым режимы ачыкланган археологик мирас объектларының сакланышын тәэмин итү, шулай ук 73-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә гражданнарның күрсәтелгән объектларга керүен һәм археологик кыр эшләрен уздыруны тәэмин итү шартларында Россия Федерациясе Су кодексында билгеләнгән эшләрне башкару мөмкинлеген күздә тота.